# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в статью 9 Закона Республики Татарстан «О государственных символах Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
28 сентября 2026 года

### Статья 1

Внести в статью 9 Закона Республики Татарстан от 14 июля 1999 года № 2284 «О государственных символах Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1999, № 8 (I часть); 2003, № 8; 2006, № 2 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3; 2016, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2022, № 83 (часть I); 2023, № 27 (часть I); 2026, № 2 (часть I) следующие изменения:

1) часть четвертую изложить в следующей редакции:

«Государственный флаг Республики Татарстан вывешивается постоянно на объектах спорта, находящихся в государственной (муниципальной) собственности, зданиях образовательных организаций независимо от форм собственности, государственных и муниципальных учреждений, осуществляющих деятельность по реализации молодежной политики (учреждений молодежной политики), или устанавливается постоянно на их территориях.»;

2) дополнить частью пятой следующего содержания:

«Государственный флаг Республики Татарстан поднимается (устанавливается) во время массовых мероприятий, проводимых образовательными организациями независимо от форм собственности, государственными и муниципальными учреждениями, осуществляющими деятельность по реализации молодежной политики (учреждениями молодежной политики), а также во время проведения официальных физкультурных мероприятий и официальных спортивных соревнований.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
06 октября 2026 года
№ 58-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 28 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3; 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы Дәүләт флагы дәүләт (муниципаль) милкендәге спорт объектларына, барлык милек рәвешендәге мәгариф оешмалары, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлеген алып баручы дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр (яшьләр сәясәте учреждениеләре) биналарына даими элеп куела яисә аларның территорияләрендә даими урнаштырыла.»;

2) түбәндәге эчтәлекле бишенче өлеш өстәргә:
«Татарстан Республикасы Дәүләт флагы барлык милек рәвешендәге мәгариф оешмалары, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлеген алып баручы дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр (яшьләр сәясәте учреждениеләре) тарафыннан үткәрелә торган массакүләм чаралар вакытында, шулай ук рәсми физкультура чаралары һәм рәсми спорт чараларын үткәргән вакытта күтәрелә (урнаштырыла).».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 06 октябрь
№ 58-ТРЗ